**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ СТАРОКУТУШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Свежухина, дом34, с.Старые Кутуши, 423116

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ИСКЕ КӨТЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ КӨТЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

урамы,34 йорт, иске котыш авыл, 423116

Тел(84396)2-72-47
Skut.Cmn@tatar.ru

№83 12.03.2018 еел

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Иске Котыш авыл җирлеге советы утырышы**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советының 2013 елның 10 ноябрендәге 62 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы прокурорының 2018 елның 9 февралендәге 157-р номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Котыш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 10 ноябрендәге 62 номерлы карарына үзгәрешләр кертү (2014 елның 13 ноябрендәге 85 номерлы) «Салым базасын киметү хокукын раслый торган документларны салым түләүчеләр тарафыннан тапшыру тәртибе һәм сроклары» 6 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүчеләр-салым ташламаларына хокуклы физик затлар, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым чигерүе рәвешендә дә, салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы. Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслау РФ Салым Кодексының 361.1 статьясындагы 3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла. Салым түләүчеләр салым декларациясе тапшыру өчен билгеләнгән вакытта -шәхси эшмәкәр булган физик затлар ».

2. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының Интернет-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлек Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе, Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге Башлыгы А.К.Митякин